Туган авылым Сеҗедер....

Автор: Арча районы Сеҗе мәктәбенең инглиз теле укытучысы

Исмагилова Эльвира Равефовна

# Кереш

Бу материал тәрбиячеләр, укытучылар өчен мәктәп балалары белән авыл тарихы турында чара үткәргәндә кулланылыр өчен әзерләнде. Максаты: авылның элеккеге һәм хәзергесен чагыштыру, халкыбызның гореф – гадәтләрен искә төшерү, йолаларын барлау; сөйләм телен үстерү, иҗадилык сәләтен арттыру.

Сәхнә бизәлеше: презентация, борынгы тормыштан мизгелләр: сандык, бәби арбасы, өстәлдә китаплар, йон эрләү җайланмалары һ.б.

Сәхнә ябык килеш тора. Алда алып баручы сөйли.

Алып баручы: Билгеле булганча, кешеләр өч төрле вакыт мизгелендә яшиләр:

элек, бүгенге һәм киләчәк. Шуларның иң җаваплысы һәм мәшәкатьлесе – бүгенгесе, мавыктырып, үзенә тартучысы – киләчәк, ә иң бае- үткән заман. Без шул  үткән заман хәзинәсеннән, ягьни тарихтан никадәр күбрәк байлык алсак, бүгенгебез тагын да баерак, ә киләчәгебез бүген дә матуррак булачак.

Аллага шөкер, безнең якларның да хәзинәсе саекмас булып чыкты. Сугыштан соңгы авыр чорларны да җиңеп, чын мәгънәсендә имин көннәр башлангач, кешеләр киләчәк буынга калдыру өчен туган як тарихын барлый башлыйлар.

“ Матди байлыклар югалмас ул, теләсәк, теләмәсәк тә барыбыздан да кала ул, кем әйтмешли, кәфеннең  кесәсе юк. Ә менә хәтер байлыгын, тарих байлыгын- югалса, берничек тә кайтарып булмый торган байлыкны- саклауга барыбызның да хәстәрлеге кирәк” дигән девиз астында эшләгән аксакалларыбыз. Шулай итеп, алардан “ Авылым тарихы”, “Колхоз тарихы”, “Мәктәп тарихы” дигән альбомнар, аяклы энциклопедик- тере тарих булган бабаларыбыздан кульязмалар калган. Әйе, вакытның үз тарихы бар, ул – Тарих.

(Сәхнә ачыла. Экраннан да күрсәтелә. Алып баручы сәхнәдәге балалар янына кереп тыңлый. Анда аның өчен өстәл куела һәм ул андагы китапларны актарган рәвеш китерә. Салмак тавыш...)

1 нче укучы :

Сеҗе-борынгы авыл. Аның исеме Казан ханлыгы  чоры авыллары исемлегенә кергән. 19 нчы йөздәге И.А. Износков хезмәтендә авыл Мурия Мусич Сизе дип бирелә. Авылның исеме турында берничә юрама бар. Берсе буенча ул Иске Му авылыннан килгән һәм Мусич фамилиясе фамилиясе алдыннан аның чыккан урыны әйтелгән- Му , ягьни Мурия. Икенчесендә Мусич Мөрәле авылыннан, ягьни Мурияднән килгән, тегермән салган, аңарчы анда удмуртлар солы иккән. “Сеҗе” сүзе удмуртча “Солы” дигәнне белдерә. Татар халкының 1552 елдагы миграциясе  көчәйгәч, авыл тагын дазуря төшә. Удмуртлардан тыш, марилар да яшәгән авыл, татарлар, килгәч, икегә бүленә- 2 утар хасил була. Татарлар Кесмәс елгасы буйлый ике яклап тезелешеп урнаша.

2 нче укучы:

Гел сугыш, бунтлар кабатланып  торган Россиянең 1705 нче елдагы указы нигезендә, рекрут хезмәте үтәү бурычы бу якларга да кагыла һәм күп ирләр 25, 20, 12 елга рекрут хезмәтенз алына. 1899 елда берничә нәселгә җир бирелә. 12 елга бер мәртәбә генә бирелгән җир гаиләдә ир-ат булса гына бирелә. Бик  теләгән кеше  икенче кешенең шәхси җирен сатып ала ала. Шулай итеп, урамнар хасил була, хуҗалык җирләре киҗәя. Каралты-кура төзелә, авыл зурая.

3 нче укучы:

Революция еллары

Ул еллардагы бишьеллык солдат хезмәтендә, әлбәттә, бу яклар да катнаша. Авыл егетләре ул елларда Оренбург якларында гына түгел, Украина, Кырым, Кара диңгез буйларына барып җитә. Махно белән дә сугыша, Кырымда Врангель гаскәрләренә каршы тора, Деникинщинаны бастыруда

катнаша, тәүлегенә 60 км араны җәяү үтәргә тууры килгән чаклар була. Халык тифтан, кылычтан, пулядан кырыла.

Сугыш афәтенә ачлык өстәлә. 21 нче елгы тарих иң коточкычыдыр.

Хәтер... "Бер гаиләнең хуҗасы сугышка китә, хатыны, 2 баласы кала Өйдә запас булмый. Кыш. Төнлә боларга бер ир-ат килеп керә дә "кайсысын?" дип сорый. Хатын: "кызны, ул итлерәк"-" ди. Кечкенә малай мич эчендә. Ярым йокымсорап яткан 12 яшьлек Бәдәр, пычак кайраган тавшка уянып китә дә, чыгып кача. Шул китүдән ул Оренбург якларыннан авылын күрергә, үзе әби булгач кына кайтып китә. Ул елларны баздан кеше башы табылган очраклар да була. Сәяси үзгәрешләр нәтиҗәсендә, яхшы яшәгән, ләкин совет хөкүмәте мәнфәгатьләренә җавап бирмәүче утарлар таркала һәм Гарь-Хутор, Тырыш, Ирек авылларыына күченә. Хәзер инде бу авылларның берсе дә юк.

4 нче укучы:

Колхозлашу чоры

30 нчы еллар тарихка күмәкләшү чоры булып кереп кала. Ләкин колхоз берничә тапкыр оешып, берничә тапкыр тарала.

НКВД дан 12 кешене раскулачивать итәргә дигән нәрәдне  халык бер-берсен яклап, юкка чыгара.  Сөргенгә Ахун бай гаиләсе генә сөрелә. Беренче колхоз Тельман исемле була. Сугыш алды елларныда куян үрчетү буенча Бөтенсоюз күләмендә дан казана.  Татарстан Дәүләт музеенда авылдашларыбызның да исемнәре бар.

Үз тарихында колхоз "Ленин"," Коммунист", " Фрунзе", "Кесмәс", "Туган як" исменәренә алыштырыла. Беренче трактор, үгездән дә каты үкереп, 1930 нчы елда кайтып төшә.

4 нче укучы:

Тирә-юньгә даның таралмаган
Карталарда исемең юк синең.
Бар байлыгың урман тынлыгы да
Бизәнгәнең энҗе чык синең.

( Аулак өй күренеше сәхнәләштерелә)

**2 нче күренеш**

5 нче укучы

Сугыш

Сеҗе җирлегеннән сугышка 615 кеше китә, 364е чит җирләрдә ятып кала. Ватан сугышы югалтуларына соңрак, Әфган сугышы өстәлә.

6 нчы укучы**:**

Кешеләр! Әгәр сез иртә белән ефәк яфраклы гөлләрнең чәчәк атуын күрәсез икән, шул иртәдә өй каршындагы тирәктә кошлар сайравын ишетәсез икән, белегез- бу иртәнге шатлыкта сугышта үлеп калганнарның ялкынлы тормышы бар.

7 нче укучы:

Әгәр дә сезнең әбиегез, я әниегез йомшак куллары белән башыгыздан сыйпый икән, үзенең моңсу күзләре белән сезнең күзләргә тутырып карый икән, белегез- ул күзләрдә сугыштан кайтмаган бабаларыгыз, этиләрегез турында тирән сагыш бар.

8 нче укучы:

Әгәр Сез тыныч, матур өйләрдә , тату гаиләдә яшисез, иркен мәктәпләрдә укыйсыз икән, белегез- бу җирдә сезенең матур яшәвегез өчен меңләгән солдатның каны түгелгән, әбиләребезнең ачы тире түгелгән. Бу яшьлекнең кадерен, тормышның ямен белеп яшәгез, кешеләр.

9 нчы укучы: Бу тынычлыкны яулап алып биргән ветераннарга , сугыш чоры балаларына, тыл ветераннарына безнең рәхмәтебез чиксез.

Безнед теләгебез бер: Бөек Ватан сугышы, Әфган, Чечня кебек сугышлар кешелекк дөньясында соңгы сугышлар булсын иде. Кешеләрнең йөзләреннән елмаю китмәсен, бәхетле балаларның шат тавышлары тынмасын иде.

10 нчы:

Хәтердән уела күп нәрсш,

Онытыла иң гүзәл яз, кышлар.

Онытылмый үзенең иңендә

Ил данын күтәргән язмышлар.

Вакытлар үтүгә сүрелеп

Сүнәләр иң якты балкыышлар.

Сүнмиләр, яктылык сибәләр

Көрәштә кабынган язмышлар.

**ҖЫР : “Солдатлар” (сәхнәләштерелә)**

Ана- Илүзә

1 җырчы- Адилә

2 нче җырчы- Язилә

Солдат- Зөфәр

(Һәйкәл, рюкзак)

Озатып вокзаллар каршында

Маңгайдан үптеләр аналар

Тузанлы юллардан үттеләр

Дөньяны күрмәгән балалар.

( сәхнәгә солдат керә, Ана аны озата)

Балалар керделәр утларга,

Балалар сүз бирде тупларга.

Күпләре туренеп шинельгә

Алдылар еракта йокларга.

АНА ҖЫРЛЫЙ:

“Балалар, торыгыз, балалар,

Ашыгыз суына табында...

Ничә ел тормыйлар балалар

Иделдә һәм Дунай ярында...

( солдат яралы башын бәйләгән килеш  һәм һәйкәл янына баса)

Уятма, йокласын, Син, ана

Айларны, елларны санап бар

Күңелдә һаман яшь, гел бала-

Кайтмаган солдатлар, солдатлар.

Ана ул йокламый, сабые
Юрганын ачса да уяна.
Аналар йөрәге шикелле
Мәйданда мәңгелек ут яна.
Аналар йөрәге шикелле
Ут яна, уйлана, талпына
Аналар хәтере шикелле
Җил йөри курганнар артында.

**3 күренеш**

Алып баручы: Заман беркайчан да, беркемгә дә җиңел бирелмәгән. Тарих та ачысын да, төчесен дә хәтер битләренә бер-бер артлы өсти барган.

Сәхнәгә БИЮЧЕ УКУЧЫЛАР чыга һәм “КЕСМӘСЕМ” шигырен сөйлиләр:

(Слайдлардан авыл күренешләре бара)

1.Безнең Кесмәс буйларыннан
Кояш чыга, таң ата
Беләм, һәркем үзенең
Туган ягын ярата.
2. Кая барсам да, мин Сине
Сагынып кайтам, Кесмәсем,
Теләмим, барар юлларым
Синнән ары китмәсен.
3.Синдә тудым, синдә үстем
Чишмә суларын эчтем.
Күпме горурлыгы бар бит
Синдәй матур инешнең.
4.Шагыйрь улың Тәбрис тә

Сине мактап җырлаган.
Мөхәммәтең хезмәт юлын
Безнең якта башлаган.
5.Әгәр моңсу булып китсә
Барганда кояш баеп,
Безнең күңелләрне күрә
Җырчың Раил Бикбаев.
6.Руфинаң һәм Ризиләң дә
Безнең Кесмәс кызлары
Алар белән горурлана
Хәтта Казан вузлары.
7.Орденлы бит туган ягым
Күпме ул һәм кызларың
ВДНХ бүләген дә
Алган бит Баяннарың.
8.Китсә дә гел кайтып торды
Әхмәтең, Гөлчәчәгең
Тагын да матуррак бит
Кесмәсем, киләчәгең.
9.Кесмәс буе-шахматчылар,
Көрәшчеләр Ватаны.
Еракләртга таралган
Аларның Җиңү даны.
10.Үзбәк абый шәкертләре
Эшен дәвам иттерә.
Үлгәч тә яшьнәп яшәү
Тими һәрбер кешегә.
11.Саегамы әллә дисәм
Синең даның, Кесмәсем,
Тирәнәйтте Алмас абый

Исән-имин эшләсен.

12.Бездә туган, бездә үскән

Чишмә суларын эчкән.

Матурлык һәм сафлык алган

Безнең гүзәл инештән.

Шатланабыз якташлары

Күреп үзгәрешләрне

Үзебездә һәм районда

Ул башкарган эшләрне.

13.Шулай булгач, бездә дә

Эшләр артка китмәсен

Начар эшләргә хакыбыз

Юк бит безнең, Кесмәсем!

(ТАТАР ХАЛЫК БИЮЕ башкарыла)

**4 нче күренеш**

Алып баручы:

Вакыт машинасы бүген дә алга тәгәри. Вакытның тарихы хәтердә бөртекләп җыела да, хәтерләргә уелып, буыннан-буынга тапшырыла.

Тагын бер ел тарих битләренә өстәлергә тора. Россиядә һәм туган җиребез Татарстан Республикасында спорт бүгенгесе көнд инде милли традидициягә әйләнде. Логика гади: спорт өлкәсе камилләшә бара. 2018 нче елда Россиядә футбол буенча дөнья чемпионаты.

Үз халкыңның тарихын саклау – киләчәккә синең бүләгенң дигән сүз. Бүгенге Татарстан- спорт җире.

Спорт киеменнән укучылар чыга:

1:Спорт- бу бит кызык тормыш!

2:Спорт-тынычлык!

3:Спорт-безнең яшьлек!

4:Спорт-сәламәт яшәү рәвеше

5: Спорт-Сочи

6: Спорт-Универсиада

7: Спорт-Казан

(Гимнастик бию башкарыла)

СӘХНӘГӘ БАРЛЫК КАТНАШУЧЫЛАР ЧЫГА:

1 нче чыгучы сөйли башлый:

1. Юк, кирәкми миңа мәрмәр сарай
   Төкермим дә алтын-көмешкә.
   Миңа ипи белән катык ярый
   Миңа рәхәт шушы килеш тә.

   2 нче:

2. Миңа кирәк шәфәкъ алсулыгы
   Кояш чыгыш, кояш баешы.
   Миңа кирәк гөлнең иң сылуы
   Тыныч күлнең уйчан камышы.

3нче

Миңа кирәк тирән диңгез сере
Күк читендә болыт аклыгы
Миңа кирәк дусның эчкерсезе
Уйнап йөргән бала шатлыгы.

4 нче

Тирә-якны күзләп, атлап йөрим,
Таптап йөрим елга буйларын.
Йөрәгемә салып, ятлап йөрим,
Кешеләрнең якты уйларын.

5нче

Болыннарга чыгам, тау буена,
Уҗым басуларын күрергә.

Мин чәчәкләр җыям ил буенча,

Мин матурлык эзлим гомергә.

6 нчы

Туган җир-иң ерак җир

Кайтып кереп булмый һич

Чыгып китсәң аннан бер.

7 нче:

Туган җир-иң якын җир

Ул яши гел җаныңда

Хет син әллә кайда йөр.

8 нче

Туган җир- иң туйган җир

Бар да мең кат күрелгән

Юк үзгәлек, юк бер сер.

9 нчы

Туган җир- иң тансык җир.

Туфрагын ятып үбә

Мең гүзәлне күргән ир.

10 нчы:

Туган җир – иң кече җир

Тау дип көчкә менгәнең

Булып чыга гади үр.

БЕРГӘ:

Туган җир- иң олы җир

Ай-кояшлы, йолдызлы

Ил офыгы сыйган җир

И туган җир, Туган җир!

“ЯРАТЫГЫЗ!” җыры башкарыла. Залга шарлар очырыла.

Кулланылган әдәбият һәм чыганаклар:

1. Фәнис Яруллин шигыре: “Туган җир”

2. Гамил Афзал шигыре: “Мин матурлык эзлим”

3. Ләлә Камалиева “Туган авылым - Сеҗедер, кешеләре энҗедер...”

4.Мөхәммәт Мәһдиев “Без кырык беренче ел балалары”

5. Гөлсинә Хәйруллина шигыре: “Кесмәсем”